**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 17 ноябрь | № 862

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче; 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы; 2015 ел, 14 май, 341 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 643 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый совет әгъзалары гомуми санының биштән бер өлешеннән артмаган күләмдә Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфалар һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын элек биләгән затлар Иҗтимагый совет составына керә ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\862.docx